**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«09» 09 2024 ел Яр Чаллы №93

«16:52:090307:1 һәм 16:39:000000:6633 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә урнашкан каты коммуналь калдыклар полигонын киңәйтү (реконструкцияләү)» дип аталган экологик экспертиза объекты буенча әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренчел материаллары буенча җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 январендагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 29 мартындагы 31/10 номерлы карарына, Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгының 2020 елның 1 декабрендәге 999 номерлы боерыгына таянып,

## КАРАР БИРӘМ:

1. «16:52:090307:1 һәм 16:39:000000:6633 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә урнашкан каты коммуналь калдыклар полигонын киңәйтү (реконструкцияләү)» дип аталган экологик экспертиза объекты буенча әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренчел материаллары буенча сораштыру формасында җәмәгать фикер алышуларын оештырырга һәм үткәрергә.
2. Эшче төркем составын расларга (1 кушымта).
3. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (2 кушымта).
4. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинны билгеләргә.
5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2024 елның 05 09 93 номерлы карарына 1 кушымта

Эшче төркем составы

Рәис:
Хәбибуллин А.Р. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе;

Комиссия әгъзалары:
1. Сәетгәрәев Ф.М. – «Капиталь төзелеш хезмәте» МУП директоры.
2. Исхакова Г.Г. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы.

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2024 елның 09 09 93 номерлы карарына 2 кушымта

Гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибе

Әлеге тәртип «16:52:090307:1 һәм 16:39:000000:6633 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә урнашкан каты коммуналь калдыклар полигонын киңәйтү (реконструкцияләү)» дип аталган экологик экспертиза объекты буенча әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренчел материаллары буенча фикер алышуларда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм район гражданнарының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халыкның иҗтимагый фикер алышуларда катнашуы һәм район халкының проект буенча тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә Тукай районы Башкарма комитетына җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Проектның график һәм текст материаллары күргәзмәсе Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган.

3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе – җомга 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш).

4. Җәмәгать фикер алышулары объекты белән танышу вакыты: 2024 елның 10 сентябреннән 2024 елның 13 октябренә кадәр. Җәмәгатьчелек искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен кабул итү иҗтимагый фикер алышуларның бөтен срогы дәвамында 2024 елның 13 сентябрендә 00:00 сәгатьтән 2024 елның 13 октябрендә 23:59 сәгатькә кадәр үткәрелә.

5. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү өчен җаваплы зат җәмәгать фикер алышуларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук гражданнарның проект буенча тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

6. Җәмәгать фикер алышулары секретаре проект буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

7. Җәмәгать фикер алышулары башланганчы, секретарь иҗтимагый фикер алышуларда катнашучыларны терки. Теркәү битендә иҗтимагый фикер алышуларда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны күрсәтелә.

8. Җәмәгать фикер алышулары уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; проект буенча фикер алышуга – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

9. Җәмәгать фикер алышулары барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла.

10. Җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе җәмәгать фикер алышулары тәмамланганнан соң, 5 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында мәҗбүри рәвештә урнаштырылырга (халыкка җитерелергә) тиеш.